СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29.06.2021 Әгерҗе шәһәре № 10-9

Әгерҗе муниципаль районы Советыныц 2016 елның 09 февралендәге 6-8 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2016 елныц 09 февралендәге 6-8 номерлы (2017 елның 26 апрелендәге 18-8 номерлы редакциясендә) карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.9. Муниципаль хезмәткәрләр реестрыннан муниципаль хезмәткәр турындагы белешмәләрне төшереп калдыру өчен аны эштән чыгару, муниципаль хезмәт вазыйфасы булмаган муниципаль вазыйфага яисә муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләп кую, үлем (һәлак булу), шулай ук затны законсыз юкка чыккан яисә закон көченә кергән суд карары нигезендә үлгән дип тану нигез булып тора.

Муниципаль хезмәттән азат ителгән муниципаль хезмәткәр эштән азат ителгән көнне муниципаль хезмәткәрләр реестрыннан төшереп калдырыла.

Муниципаль хезмәткәр вафат булган (һәлак булган) очракта йә мунициипаль хезмәткәрне хәбәрсез югалган дип танылган яисә аны закон көченә кергән суд карары белән үлгән дип игълан иткән очракта, муниципаль хезмәткәр вафат булган (һәлак булган) көннең яисә суд карары законлы көченә кергән көннең иртәгесендә муниципаль хезмәткәрләр реестрыннан төшереп калдырыла.»

2. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе турында» 2013 елның 19 августындагы 26-4 номерлы Әгерҗе муниципаль район Советы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының законлылык, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комитетына йокләргә.

Муниципаль район Башлыгы,
Совет Рәисе А.Р. Вәлиев